# Татар язучыларының афоризмнары, хикмәтле сүзләре, фәлсәфи уйланулары

Без - татарлар, телебез - татар теле, мөстәкыйль һәм төзек кагыйдәле камил тел ул

**К.Насыйри**

Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәкемнән миндә туган телебезне сөю тугъды. Әгәр миңа җырулар ярдәм итмәсә, мин соң... туган телебезне сөймәк кеби бер олугъ нигъмәткә малик була алыр идеммени? Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!

**Г.Тукай**

Халыкның теле - аның рухи тормышының иң яхшы, беркайчан да шиңми, мәңге яшәреп тора торган иң матур чәчәге. Телдә халык һәм аның Ватаны җанлы рәвештә гәүдәләнә, телдә халыкның бөтен рухи тормышының тарихы чагыла.

**К.Ушинский**

Милли тел язмышы ул - милләт яшәешенең нигезе. Телнең зәгыйфьләнә баруы ул - милләтнең юкка чыга баруының күрсәткече. Милләт ул - теле булган халык. Милли тел язмышы ул - милләт язмышы, аның яшәеш, үсеш формасы, милләтнең сакчысы да, аның киләчәгенең гарантиясе дә. Кешелек әле милләтнең төп таянычы булган, йөрәк парәседәй нечкә, кадерле башка төр могҗизаны уйлап тапмаган, таба да алмас, бу бөек көчне бернәрсә дә алыштыра алмый. Чыгышы белән татар булса да, үз телен белмәгән, шул ук вакытта үз халкын яраткан, аны сөйгән кеше дә милләтнең сакчысы, аның үсешенә өлеш кертә алган зат була алмый...

И туган телем, мөкатдәс моңым, яшәешемнең бөек мәгънәсе булган могҗизам!

**Ә.Кәримуллин**

Тел ул - бөтен халык казанышы, меңнәрчә, миллионнарча кешеләрнең күп гасырлык иҗат җимеше. Шуңа күрә дә телгә карата башбаштаклык кылырга, аның белән саксыз эш итәргә, аны үзенә ошаганча бозарга беркемнең дә хакы юк.

Тел - халыкның, милләтнең иң беренче, иң әһәмиятле билгесе. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү - мәдәниятле, зыялы һәр кешенең изге бурычы.

**Р.Йосыпов**

Туган тел ул тәндә, җанда калсын Ана сөте булып гомергә.
**И.Юзеев**

Әдип вә галимнәре булмаган кавем- бәхетсез, мәшһүр кемсәләрен оныткан халык көчсез, әдәбияты булмаган милләт - рухсыз.

(***Ризаэддин Фәхреддин***)

Әгәр дә милләтне көчле итеп, бөек итеп күрәсең килә икән, иң беренче булып аның көчен таны, шул милләтнең баласы булуың белән горурлан.

**(*Туфан Миңнуллин)***

Тураерга биле булса,
Күтәрергә иңе булса,
Авызында теле булса-
Димәк, әле халык исән!

***(Фәнис Яруллин)***

Кеше күңеле өчен туган як кирәк. Еракка китсә- сагыныр өчен, картайса- балалыгына кайтыр өчен, дошман керсә- яклар өчен. Ерак җирләрдә йөргәндә, кеше читтәге матурлыкны әнә шул үзенең туган ягы белән чагыштыра. Туган ягы аңарга биеклеккә сикерү ноктасы, гүзәллек үрнәге булып хезмәт итә.

***(Фәнис Яруллин)***

Туган җирен яраткан кеше генә бөтен дөнҗяны ярата ала.

***(Галимҗан Гыйльманов)***

Уе юкның- теле юк,
Теле юкның - иле юк.
Илен санга санамаган
Телсездән дә тиле юк.

***(Нури Арсланов)***

Керләнә өсте- өстенә рух, һич хозур вөҗданга юк;
Ни сәбәптән Җир йөзендә тәнгә мунча, җанга юк?!

***(Габдулла Тукай)***

Сүзне төрлечә әйтеп була. Бер үк сүзгә теләсәң - шатлык, теләсәң - кайгы, кирәк чакта ихтирам яисә нәфрәт сыйдырып була. Сүз - шул ук, ә аның тәэсире тулысынча үзгә. Искиткеч нәрсә ул - сүз.

***(Миргазиян Юныс)***

Туган тел ул- бездән соң да
Яшәр өчен туган тел.
Бүгенгедән киләчәккә
Дәшәр өчен туган тел.

***(Зиннур Насыйбуллин)***

Исәнләшик.
Мин - халкыңның теле,
Кылыч телгәләгән хәтере.
Сиңа мине "үлде" дигәннәрдер,
Мин исән-сау, мин бар, мин тере!

***(Рәшит Әхмәтҗанов)***

Сүз, кош кебек, бер авыздан очса - тоттырмый. Әгәр бик күп сөйләнеп йөрсәң, аягыңа да урала.

***( Нәбирә Гыйматдинова)***

Сүз - могҗиза ул! Сүзгә ияреп, уй чыга, димәк, акыл, хәтер суырылып чыга... Сүз сихердән өстен, ырымнан алда йөри. Сөйләшкән кешене, сүз белгән кешене юлдан яздыру кыен.

***(Галимҗан Гыйльманов)***

Җирдән китү - үлем түгел әле,
Исән булса сине белгәннәр..
Чын үлемең килер,
Сине белгән
Соңгы кеше гүргә кергәндә.

***( Харрас Әюп)***

Беркем дә булдыра алмаганны эшләп, беркемгә дә кирәкмәгәнеңне тоеп яшәүдән дә авыр нәрсә юк.

***(Марат Кәбиров)***

Кешеләрне шатландыруың - үзеңне шатландыруыңдыр**.**

**( Ризаэддин Фәхреддин)**

Кояш - чыгышта, кош - очышта, кеше юмартлыкта матур.

***(Мөсәгыйт Хәбибуллин)***

Дуслык - кайгыны, шатлыкны уртаклашудыр**.**

***(Ризаэддин Фәхреддин)***

Якутлар табыладыр вакыт белән,
Вакытлар табылмыйдыр якут белән.

***(Габделҗаббар Кандалый)***

Вакыт - иң сыналган, иң яхшы дәвалаучы ул.

**(*Әмирхан Еники)***

Вакыт кадерен белмәүчегә сәгать телен күрсәтә.

***(Шәүкәт Галиев)***

Ни белән үлчәнә гомер?
Калган эзләр белән,
Кеше күңеленә орлык итеп
Салган сүзләр белән.

***(Саҗидә Сөләйманова)***

Җан тыныч булсын өчен, вөҗданыңа ешрак күз салырга, аның тавышын тыңларга кирәк.

**(Фәнис Яруллин)**